ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

ул. Нефтяников, д.30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

Нефтьчеләр ур., 30 нчы йорт, Мәлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592) 3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 18 » февраль 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясеннән узучы, «Мәлбагыш» һәм «Мәллә» елгаларының исемнәрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында географик объектларның исеме өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 23 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, тарихи исемнәрне саклау, максатыннан, **карар итәм:**

1. 2021 елның 22 мартында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясеннән узучы «Мәлбагыш» һәм «Мәллә» елгаларының исемнәрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
2. Уздыру урыны: Татрстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы, Җәлили урамы, 4 нче йорт, авыл Мәдәният йорты бинасы. Ачык тыңлаулар үткәрү вакыты - 17.00 сәгать.
3. Ачык тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр 2021 елның 21 мартына 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Мальбагыш авылы, Нефтьчеләр урамы, 30 нчы йорт.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан

итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.Ю.Әхмәтшин